РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
САРМАНОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
«ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ул. Молодежная, д. 1 а,
с. Лешев Тамак, 423353.
Телефон: (85559) 4-13-24
E-mail: Levtam.Sar@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яшьләр урамы, 1 а йорт,
Ләшәү Тамак авылы, 423353.
Телефон: (85559) 4-13-24
E-mail: Levtam.Sar@tatar.ru

ОГРН 1021601312182 ИНН/КПП 1636001322/163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 07 май № 6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Советның 2017 елның 21 августындагы 19 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексына, Сарман районының 2021 елның 24 мартындагы 02-07-01-21 номерлы прокуратура протестына туры китерү максатыннан, Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Советның 2017 елның 25 августындагы 41 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**4 бүлекнең 21 пунктында** «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә.

**5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6.1 пункт** өстәргә:

«6.1. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар әлеге вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.».

**13 бүлекнең 1 пунктындагы 4 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәтен узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү.».

**13.1. бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт** өстәргә:

«4.1. Конкурста катнашырга теләк белдергән граждан җирле үзидарә органына тәкъдим итә:

1) шәхси гариза;

2) муниципаль хезмәткә керә торган граждан тарафыннан җирле үзидарә органына тапшыру өчен федераль законнар нигезендә расланган форма буенча, фотографияны да теркәп, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

3) паспорт күчермәсе (паспорт конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

4) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (эш (хезмәт) эшчәнлеге моңарчы башкарылмаган очраклардан тыш);

5) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон нигезендә гражданның муниципаль хезмәткә керүгә һәм аны узуга комачаулаучы авыру булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

6) граждан беренче тапкыр көндезге уку формасы буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчалары исәбеннән урта һөнәри яки югары белем алуын раслый торган, шулай ук ул үзләштерә торган мәгариф программасы турында (һөнәрнең исемен, белгечлек яки әзерлек юнәлешен күрсәтеп), граждан тарафыннан уку планы нигезендә арадаш аттестацияләр узу нәтиҗәләре турында, белем бирү оешмасының уставында һәм эчке тәртип кагыйдәләрендә каралган бурычларны үтәү турында белешмә.

7) язма бирем (конкурс комиссиясе тарафыннан кулланыла торган конкурс процедураларының берсе язма бирем булса).».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Советы Рәисе И.З.Хабибуллин